Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«11» ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы территориясендә теркәлгән, 1 гр. инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- янгыннан саклау җиһазы сатып алу.
- Иске Әлмәт торак пунктының 62 нче скважинасы янындагы территорияне төзекләндерү, су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча ремонт эшләре үткәрү.

Халык җыенында рәислек итүче Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов